СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2025 Баулы шәһәре 289

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль район Советының
2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы
карары белән расланган, Татарстан
Республикасы «Баулы муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында»
Баулы муниципаль районы Советы
карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районы Советы карары проектын (1нче кушымта) хупларга һәм фикер алышуга куярга, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Карар проектын 1нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

3. Расларга:

- гражданнарның «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан

Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2-нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3нче кушымта).

4. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга:

5. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү буенча (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркемен түбәндәге составта төзергә:

1. Попов Сергей Александрович - эш төркеме рәисе.
2. Даутов Марсель Гәбделмәҗит улы - эш төркеме әгъзасы.
3. Зәбирова Әлфия Рафаил кызы - эш төркеме әгъзасы.

6. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213

номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районы Советының карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2025 елның 5 мартында 15.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында уздырырга: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20нче йорт.

7. Эш төркеменә «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы карарлары, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы депутатлары һәм гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы муниципаль районы Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Баулы муниципаль район
Советы рәисе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль район
Советының 2025 елның ________
____номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы

муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»
Баулы муниципаль районы Советы карары
ПРОЕКТЫ

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Муниципаль берәмлекләрнең атамалары турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 25 декабрендәге 10/13-09/6137 номерлы хаты нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кыскартылган атамасы – «Баулы муниципаль районы».»;

6 статьяның 1 пунктындагы 13) пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә;

6 статьяның 1 пунктының 39 пунктчасын) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39) әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чаралар оештыру, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм үткәрү;»;

48 статьяның 3) пунктчаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чаралар оештыра, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә

муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыра һәм үткәрә;

48 статьяның 6) пунктчасының беренче абзацында «Россия Федерациясе субъекты) сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыра» сүзләрен өстәргә;

37 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.2 пунктча өстәргә:

«9.2) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

81 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Районның җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыралар.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң кабул итү турындагы карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баулы муниципаль район
Советының 2025 елның ________
_____номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Баулы

муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу
ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карар проектына карата тәкъдимнәр Баулы муниципаль районы Советына язма рәвештә түбәндәге адрес буенча кертелә: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20нче йорт.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар шәхсән яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 423930, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт (конвертка “Устав буенча фикер алышу” яисә “ачык тыңлаулар” дигән тамга куеп).

Баулы муниципаль район
Советының 2025 елның _______
____номерлы карарына
3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру
ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (2022 елның 14 сентябрендәге 128 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 213 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 253 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 283 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карар проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба - ачык тыңлаулар) Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Ачык тыңлаулар уздыру комиссиясенә ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район кешеләре үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнаша ала.

3. Чыгыш ясау катнашу хокукыннан башка ачык тыңлауларда районның барлык кызыксынган халкы катнашырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 1 сәгать алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлек Башлыгы яисә аның кушуы буенча муниципаль берәмлекнең башка вазыйфаи заты рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар уздыру тәртибе турында хәбәр итә торган рәиснең кереш сүзе белән ачыла.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне исәпкә алу өчен, рәис тәкъдиме буенча, җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эш төркеме әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам

итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан да артык түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар утырыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәис рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртип саклау ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучы ачык тыңлаулар уздыру тәртибен бозган очракта, рәис аны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамлангач, рәис ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне төгәлләштерү өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә кушып бирелә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалан һәм билгеләнгән тәртиптә Совет материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эш төркеме тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы Аппараты тарафыннан тормышка ашырыла.